Сөй гомерне, сөй халыкны, сөй халыкның дөньясын!

ДУСЛЫК

ОКТЯБРЬ РАЙОНЫНЫҢ ИҖТИМАГЫЙ СӘЯСИ ГАЗЕТАСЫ

ОБЩЕСТВЕННО ПОЛИТИЧЕСКАЯ ГАЗЕТА ОКТЯБРЬСКОГО РАЙОНА.

Газета 1931 елның 9 июленнән бирле чыга | №105 (7278) | 3 сентябрь, 1991 ел. СИШӘМБЕ | Бәясе 4 тиен.

2 сентябрьдә Мәскәүдә СССР халык депутатларының V чираттан тыш съезды ачылды.

СССР Югары Совет сессиясе

КАРАРЫ

МӘСКӘҮ (ТАСС). СССР Югары Советының чираттан тыш сессиясе җомга көнне түгел, ә шимбә көнне —31 августта гына тәмамланды. Фикер алышуга куелган мәсьәләләр бик катлаулы булып чыкты. Шуның белән бергә алга китешкә кайчак кворум җитмәү дә комачаулады.

Союз парламенты соңгы ике йомгаклау көнендә шактый документлар кабул итте. Аларның берсе—дәүләт перевороты ясауга омтылышны кире кагу буенча кичектергесез чаралар турында карардан гыйбарәт.

Шуңа бәйле рәвештә СССР халык депутатларының чираттан тыш V съезды алдында СССР Конституциясенә кайбер үзгәрешләр кертү һәм кайбер норматив актлар кабул итү бурычы тора.

СССР Конституциясен бозуда гаепле булган, урыннардагы кешеләрне җаваплылыкка тарту турындагы мәсьәләне хәл итү өчен парламент комиссиясе төзү, һәм РСФСР Югары Советының бу комиссиясе эшчәнлеге һәм вәкаләтләрен төзү тәртибе турындагы Закон проектын карау буенча фикер алышу шактый озакка сузылды. Һәм, ниһаять, Югары Совет Закон кабул итеп составына 15 кеше кергән комиссиянең үзен дә төзеде.

Депутатлар алдында кыска гына мөрәҗәгать белән Союз Советы рәисе И. Д. Лаптев чыкты. Ул, атап әйткәндә, хәзер күп кенә депутатларның СССР Югары Советы члены вәкаләтләрен үз өсләреннән төшерү турында гариза бирә башлауларын хәбәр итте. Моңа этәрүче хисләр аңлашыла, —диде палата җитәкчесе. Шул ук вакытта,—дип дәвам итте ул, —нәкъ менә бүген, парламентның объектив һәм субъектив уңышсызлыклары шулай ачык рәвештә калыкканда, ул республикалар, политик партияләр, башка иҗтимагый көчләр арасында һәммәсе өчен бердәнбер ачык күпер булып калды. Шуңа күрә, безнең күпме генә эшлисе калуга да карамастан, бу җаваплылыктан качалмыйбыз. Бу күпер аша безнең каршыга үзара аңлашу һәм үзара ярдәм агымнары килсен өчен барысын да эшләргә кирәк, дип сүзен йомгаклады И. Д. Лаптев.

СССР халык депутатлары съезды ачылу

МӘСКӘҮ. 2 сентябрьдә Кремльнең Съездлар сараенда СССР халык депутатларының V чираттан тыш съезды ачылды. Алар алдында 19—21 август фетнәсенең уңышсызлыгыннан соң илдәге хәлгә бәя бирү, әлеге фетнә омтылышының соңгы нәтиҗәләреннән котылу һәм мондый вакыйгаларга киләчәктә юл куймау буенча чаралар күрү бурычы тора.

СССР Югары Советы Карары белән узган атнада съездның көн тәртибенә кертү өчен түбәндәге мәсьәләләр тәкъдим ителде: илдәге сәяси хәл һәм дәүләт фетнәсе нәтиҗәләрен юкка чыгару буенча чаралар турында; СССР Югары Советы рәисе турында; СССР вице-президенты турында, кеше хокуклары һәм азатлыгы декларациясе турында; Литва, Латвия, Эстония республикаларының аларның бәйсезлек Декларацияләрен тану турындагы мөрәҗәгатьләре хакында; СССР Югары Советының составын яңарту турында; СССР Конституциясенә һәм ССР Союзының башка законлылык актларына үзгәрешләр кертү турында; СССР генераль прокуроры турында; СССР халык депутатлары съездының мандат комиссиясе рәисе турында.

Съездда илдәге хәл турында доклад белән СССР Президенты чыгыш ясар дип уйланылган иде. Әмма алдагы көнне генә М. С. Горбачев теле-интервьюда съездда республика җитәкчеләреннән булып узган очрашуда эшләнгән уртак позиция турында килешенгән Белдерүләре игълан ителәчәген хәбәр итте.

Съездның беренче утырышы башлангач, депутатлар фетнә көнендә һәлак булганнарны хөрмәтләп искә алдылар.

Аннан соң СССР Президентының һәм союздаш республикаларның югары җитәкчеләренең Белдерүен Казахстан президенты М.А. Назарбаев укыды. Белдерүдә, атап әйткәндә, суверен дәүләтләр союзы турында Килешү төзергә һәм барлык теләгән республикаларга союзда үз өлешләрен мөстәкыйль рәвештә билгеләп, аңа кул куярга тәкъдим ителә. Шулай ук республикалар арасында һич кичектергесез экономик союз төзү турында да тәкъдим бар.

Моннан соң тәнәфес игълан ителде, һәм шул арада депутатлар Белдерү тексты белән танышып аңа карата фикер тупладылар.

«Игенче» колхозында комбайнчы һөнәре династиядән килүче гаиләләр байтак. Шуларның берсе—Абдрахмановлар.

«Кемнең кемлеге эшеннән күренә»,—диләр. Абдрахмановлар үзен нәкъ шул яктан күрсәтә дә. Урып-җыю чорында кырда алар хуҗа. Икмәк өчен бөтен җаваплылыкны тоеп, югалтуларсыз җыеп алырга ашкындылар алар. Азат ага үзе «Нива» комбайнында. Өч улын кече яшьтән техника эшенә өйрәтте, үзенә ярдәмче итеп алды. Олы улы Ринат та шул юлны сайлады, хәзер колхозда техника буенча белгеч. Ә икенче улы Рәис исә быел ашлык суктыруда колхозда әйдәп баручы комбайнчы, исеме районның әйбәт суктыручылар исемлегеннән төшмәде. Улларының шундый уңгач, эшкә батыр булуларында ата тәрбиясе зур роль уйнагандыр, әлбәттә. Тикмәгә генә алар гаиләсе хакында сөйләгәндә, бүгенге эшне иртәгә калдырмыйлар,—диләр.

Урып-җыюны үз вакытында төгәлләүдә дә аларның өлеше зур булды.

Рәсемдә: А. Абдрахманов комбайны янында.
Н. Азизов фотосы.

Сентябрь кыңгыравы

Чәчәктәй киенгән балалар ак күбәләкләрне хәтерләтәләр. Табигый чәчәкләр тоткан укучылар тулы мәйдан, әйтерсең лә, кечкенә болын. Бер читтә дулкынланган ата-аналар да басып тора. Алар беренче кат мәктәп бусагасын атлап үткән нарасыйларына яратып та, сокланып та карыйлар.

Беренчеләр һәм өлкән класслар... Ата-аналары, укытучылары өметләрен акларлармы? Уртак тырышлыклары бушка китмәсме? Хәзергә бу хакта берәү дә, берни дә белми. Әлегә тантаналы линейка бара.

Беренче башлап сүзне беренче урта мәктәп директоры Равил Габдрахманович Билалов ала:

—Кадерле балалар!—ди ул. —Сезне яңа уку елы белән тәбрик итәм. Сезгә уңышлар, ныклы сәламәтлек телим.

Аннан директор быелгы елда мәктәпкә яңа укытучылар килүе, кадрларга мохтаҗлык булмаячагы, бик кыенлык белән булса да һәммә укучының да дәфтәрләр белән тәэмин ителүе, ә мәктәп формасының һаман да үзгәрешсез калачагы турында әйтеп үтә.

Соңыннан сүзне шефлар ала. Норлат разведка бораулавы идарәсенең баш инженеры Ю. Карпов, ит комбинаты директоры, мәктәп советы председателе Р. Чахмахчев та балаларга киләчәк юлларында уңышлар телиләр.

Мәктәпкә ярдәм итү йөзеннән шефлар зур көч куйганнар. «Заречный» пионерлагеренда рәхәтләнеп ял итеп кайткан Наташа Маркова, Наташа Андреева һәм башкалар җәйге чорның кызыклы узуыннан бик канәгать.

Көмеш чыңлы кыңгырау чыңлый. Беренчеләр өчен бу беренче, ә өлкәннәр өчен соңгы... сентябрь кыңгыравы.

Г. РӘХИМОВА.

„Сездән башка күңелсез“

—Сез юк чакта мәктәптә күңелсез тынлык хөкем сөрде, сез килүгә бөтен нәрсәгә җан керде,—дип башлады үзенең чыгышын ярдәмче интернат-мәктәп директоры Виталий Ермолаевич Ефимов. Уку елының беренче көне—белем бәйрәме биредә шулай башланды.

Мәктәп быел укучыларны бик җылы каршы алды. Вестибюльгә элеккечә генә кермисең: биредә табигатьнең бер почмагына килеп чыккандай буласың: янда гына —яшел урман, зәңгәр күктә кошлар оча. Коллектив ремонтны үз көче белән ясаган. Сүз уңаеннан әйтергә кирәк: интернат-мәктәп бинасына быел 30 ел тулды, ә мәктәп үзе 28 нче уку елына керә.

Биредә коллектив тотрыклы. Мәктәпнең ачылу көненнән башлап балаларга аң-белем бирүгә көч куючылар бар. Алар — башлангыч класслар укытучысы Людмила Дмитриевна Куницына, хезмәт укытучысы Михаил Васильевич Спасов һәм башкалар. Хезмәт тәрбиясе бирү буенча мәктәп аеруча мактауга лаек. Укучылар бик теләп агачтан бизәкләп әйберләр ясау белән шөгыльләнәләр. Хезмәтләре төрле ярминкәләрдә урын ала. Моны Михаил Васильевичның хезмәт казанышы дисәк, хата булмас.

Быел биредә 180 бала укыячак. 15е беренче класска бара. Уку елын ачып җибәргән, кечкенә мәктәпләргә хас тыйнак кына линейкада, укытучылар укучыларны, ата-аналарны, килгән кунакларны бәйрәм белән тәбрикләделәр.

Ф. ГАЛИМОВА.

Азык хәзерлиләр

Хафизовлылар мул азык базасы хәзерләү өчен зур көч куеп эшлиләр.

Хәзерге вакытта кукурузны силоска уру эшләре бара. Сусыл азыкны урдыруда Александр Илеверов вакытны нәтиҗәле файдаланып, зур тырышлык куеп эшли. Чабылган яшел массаны базга ташып торучы шоферлар Владимир Ильдухин, Әхәт Шәйдуллин, Хәниф Рәхмәтуллин, Виктор Таймуллин көненә 12—13 әр рейс ясыйлар. Силосны базда Минхаят Гыйниятуллин, Ямаш Бикиев тыгызлап торалар. Бу эш хәзер дә дәвам итә.

Т. ДЕРБЫШЕВ.

Терлекчелек—удар фронт

Диплом яулаган хуҗалыкта

1990—1991 елдагы кышлату чорын «Рассвет» совхозы терлекчеләре уңышлы төгәлләделәр. Катлаулы шартларда эшләп тә, башка күп хуҗалыклардан аермалы буларак, һәр тармактан продукция алу алдагы кышлатуга караганда шактый үсте. Моны саннар ачык раслый. Совхоз уңганнары алда күрсәтелгән чорда 3380 центнер ит җитештерүне тәэмин иттеләр. Бу 1989—1990 елдагы кышлату чоры белән чагыштырганда 20 процентка артык дигән сүз. Сөт җитештерү исә 22490 центнерга җитте, үсеш 15 процент күләмендә булды.

Җитештерүнең артуы бу төр продуктларны хәзерләүне күбәйтү мөмкинлеге тудырды. Ит хәзерләү буенча дәүләт заказы 106 процент, ә сөт 110 процент итеп башкарылды.

Соңгы кышлату барышында мондый нәтиҗәләр районда гына түгел, республика күләмендәге ярышта алдынгы урын яуларга мөмкинлек бирде. Кышлату чорына билгеләнгән шартларны уңышлы үтәгәне, терлекчелек продукциясе алуны арттыра баруны тәэмин иткәне өчен совхоз республика күләмендәге ярышта җиңеп чыккан 17 хуҗалык сафына басты. Бөтенроссия социалистик ярышында югары нәтиҗәләргә ирешкән өчен совхоз ТССР Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының һәм агропромышленность комплексы работниклары профсоюзы рескомының 1991 елның 23 июль карары нигезендә Мактау дипломы һәм 3 мең сум акча белән бүләкләнә. Шул ук карар нигезендә хуҗалыкка чираттан тыш автобус яисә җиңел автомобиль сатып алу хокукы бирелә.

—Хуҗалык терлекчеләре үз алларына куелган бурычларны намус белән үтәп чыгу өчен тырышлыкларын куеп эшләделәр һәм эшлиләр,—диде бу унайдан совхоз директоры Харис Нуруллович Атауллин. — Мондый уңышка без аренда коллективларының максатчан хезмәте белән ирештек.

Хуҗалыкта һәр тармакта аренда мөнәсәбәтләре кертелгән. Һәм аренда звенолары берничә ел рәттән стабиль эшләп киләләр, күрсәткечләрен . яхшырта баралар.

Товарлыклы-сөтчелек фермасында һәр бүлекчәдә берничә шундый коллектив эшли. Беренчесендә Шамил Саттаров, Фатыйх Билданов, Розалия Манапова җитәкләгән звенолар гел унганлык күрсәтәләр. Зөлкәрнәй Гобәйдуллин звеносы да (сез аларны рәсемдә күрәсез) башка күршеләре белән ярышта сынатa торганнардан түгел. Икенче бүлекчәдә Илдус Туктамышев, Ринат Тимербулатов һәм Рәшидә Шәрәпова звенолары членнарының да эшкә дисәң җиннәре гел сызганулы.

—Ит җитештерүдә төп продукцияне товарлыклы-дуңгызчылык фермасы бирә, —ди совхоз экономисты Вәгыйзь Сатдаров. —Тулаем итнең 60—65 проценты алар өлешенә туры килә.

Тәзкирә Абдуллина җитәкләгән бу ферма да аренда подряды нигезендә эшли. Мөгезле эре терлекләрне җәйге сезонда Рушан Хәсәенов, Хәниф Гыйззәтуллин, ике адаш—Маняпов һәм Әхмәтов Рифкатьләр җитәкләгән арендачылар симертә. Алар караган маллар да көр, тиз үсәләр, югары артым бирәләр.

Мөгезле эре терлекләрне совхоз килешү нигезендә халыкка да тарата. Ел саен 500—550 баш яшь малны эшчеләр өйләрендә үстерә. Совхоз аларны сусыл, яшел азык белән тәэмин итә, фуражын да бирә. Тиешле көрлеккә җиткәч, хуҗалар аны совхозга алдан килешенгән бәя белән саталар. Бу һәр ике як өчен отышлы.

Диплом яулаган хуҗалык терлекчеләре бу көннәрдә ирешелгәннәрне ныгыту, еллык дәүләт заказларын үтәү өчен көрәшәләр, яңа кышлату чорына һәрьяклы хәзерлек алып баралар.

Р. АЙЗАТУЛЛИН.

● Безгә язалар

ЗАРУРИ ТАЛӘП

Бер төркем кешеләрнең мәчет салырга урын сорауларына җавап итеп, быел район Советы башкарма комитеты әлеге үтенечне канәгатьләндергән уңай карар кабул итте. Бу карарда яңа мәчетне мөселман зираты янәшәсендәге мәйданчыкта салырга рөхсәт ителгән иде. Әмма без, өлкән буын вәкилләре мәчетне чын-чынлап кирәк сенүчеләр бу карар белән танышкач, бер дә канәгатьлек тоймадык. Чөнки зират янәшәсендәге урын аксакаллар тарафыннан (аларның күбесе . хәзер мәрхүм дә инде) киләчәктә нәкъ менә зират мәйданын үстерү өчен васыять ителгән җир ул. Инде моның белән санашырга теләмәгән очракта да, әлеге урын мәчет салу өчен кулай түгел. Беренчедән, мәчетләр беркайчан да зират янәшәсенә салынмыйлар. Бу — гомердә дә күрелгән хәл түгел. Динебезгә ят күренеш дисәк тә дөрес булыр. Икенчедән, татар мәчетләре, гадәттә торак пунктның читенә салынмыйлар, ә халыкның күпләп туплантан, тыгыз урнашып яшәгән җирендә булалар. Өченчедән, мәчет бинaлары үзләренең күп гасырлык камил төзелеше белән шәһәр (яки авыл) күренешенә үзенчәлекле ямь өстәүче сәнгати архитектура корылмасы дип тә санныйбыз без. Шуңа күрә аның урыны үзәктә булу—зарури таләп. Һәм моны шәһәребезнең әлеге мәсьәләгә кагылышы булган җаваплы кешеләре дә исәпкә алсыннар иде.

В. ГЫЙЛЬМЕТДИНОВ.
һ.б. барысы 71 имза.

Савымчының уңганлыгы хезмәт нәтиҗәләрендә күренә диләр. Әлфия Сәлахова бу яктан сынатa торганнардан түгел инде. Агымдагы елның җиде аенда ул үз группасындагы һәр сыердан 2070 килограмм сөт савып алуга ирешә, бу колхоз күрсәткеченнән күпкә артык.

Хәзер хуҗалык терлекчеләре җәйләүнең соңгы этабында сыерлардан сөт савуны киметмәү өчен тырышалар. Әлфия дә кулыннан килгәннең барысын эшли.

Рәсемдә: «Татарстан» колхозы сыер савучысы Әлфия Сәлахова.

Яңадан теркәү үткәрелә

Соңгы елларда үзгәртеп кору тәэсире астында хезмәт коллективларының күп кенә төрләре барлыкка килде. Безнең район территориясендә дә традицион предприятиеләр, оешмалар һәм филиаллар белән бер рәттән аренда коллективлары, кооперативлар, төрле максатлардагы кече предприятиеләр эшли башлады. Моннан тыш, традицион предприятиеләрнең исемен, аның юридик дәрәҗәсен үзгәртү тенденциясе булды. Югыйсә аларның эше тулысынча хуҗалык исәбенә корылган һәм алар мөстәкыйль балансқа ия. Барлык исем үзгәртүләрнең асылы-мәгънәсе җитештерүне арттыру, материаль-техник базаны ныгыту һәм эшләүчеләрнең социаль хәлен ныгыту максатына кайтып кала.

Төрле предприятиеләрнең барлыкка килүенә бәйле рәвештә һәм оештыру документларын тәртипкә салу максатында ТССР һәм РСФСР тарафыннан Законнар да кабул ителде. Алар нигезендә халык депутатларының район Советы август-сентябрь аенда дәүләт реестрына кертү өчен моңа кадәр яшәп килгән предприятие, оешмаларны яңадан теркәү, ә яңаларын дәүләт теркәвенә алуны үткәрергә карар кылды.

Хуҗалык исәбендәге, үз балансы, үз счеты, юридик йөзе булган барлык промышленность, төзелеш, транспорт оешмалары һәм предприятиеләре, колхозлар, совхозлар, кооперативлар, кече предприятиеләр, структур бүлекчәләр үзләренең оештыру-хокук формаларына, милек һәм эшчәнлек төрләренә карамастан, теркәү һәм яңадан теркәүне узалар.

Шуңа күрә предприятиеләрдәге комиссияләр кыска вакыт эчендә Уставны җентекләп карап чыгалар, соңгы елларда кабул ителгән карарларга бәйле рәвештә төзәтмәләр кертәләр, аннан соң предприятиене теркәү яки яңадан теркәү хакындагы гаризаны ике нөсхәдә язып халык депутатларының район Советы башкарма комитетына мөрәҗәгать итәләр. Гаризага предприятиенең уставы, оешу турындагы карары яки оештыручыларның килешүе, дәүләт салымын түләүне раслаучы документ теркәлә.

Шушы документларны өйрәнгәннән соң аның дәүләт теркәвенә алынуы яки яңадан теркәлүе хакында таныклык бирелә.

Барлык бу чаралар республика күләмендә үткәреләләр. Шуңа күрә җитәкчеләр һәм исәп-хисап хезмәткәрләре тиешле документларны хәзерләүне тизләтергә тиешләр.

М. СИРАЕВ,
райфонның анализ һәм экономика бүлеге начальнигы.

ТУГАН ИЛЕБЕЗДӘ

Товар биржалары

Экономикада хәлләр тотрыклы булмаганга күрә СССРдагы товар биржаларының күбесе беренче айларда бартер килешүләренә җайлашты. Алыш-биреш түбәндәгечә: 20 мең тонна иткә автомобиль; бер вагон шикәргә автокран, бер цистерна бензинга—5 вагон шифер алып була. Монда хәзер әйләнештә акча йөрми диярлек. Хәл акрынлап үзгәрә.

(ТАСС).

Тагын бер мәшәкать өстәлде

Кормыш микрорайонындагы 195 нче йортны эксплуатациягә биргәндә бик күп төрле җитешсезлекләр белән тапшырганнар иде. Күп балалы гаиләләр һәм ялгыз яшәүче картлар әнә шул сәбәпләр аркасында бүген дә иза чигәләр әле. Инде менә тагын бер мәшәкать өстәлде. Ул газ мәсьәләсе. Узган елда йортка газ кертәбез дип торбалар да китереп бушаттылар һәм урнаштыра да башлаганнар иде. Без, пенсионерлар, моңа бик шатландык. Ләкин иртә куанганбыз икән. Газ торбасы сузучы эшчеләрнең шул көннән бирле күренгәннәре юк. Ә күршебездә генә, Нурлат разведка бораулавы идарәсендә хезмәт куючы эшчеләрнең гаиләләре бу вакытта рәхәтләнеп зәңгәр ягулыктан файдаланып яталар. Көнләшерлек тә шул. Юкса, безнең дә рәхәт тормышта яшисе килә.

Газ мәсьәләсе турында шәһәр Советына бик күп тапкырлар мөрәҗәгать итсәк тә, безнең үтенечкә колак салучы да, әһәмият бирүче дә юк.

Ярый әле торак-коммуналь хуҗалыгы идарәсе көнкүлебезне тынычландыра, «быел кирәчәк» дип өметләндерә. «Өметсез шайтан», диләр аңысы. Ләкин алда яңгырлы кара көз һәм салкын кыш торганын да онытып җибәрмик. Без, мохтаҗлар, нишләрбез? Кайберәүләр шикелле бетен уңайлыклары да булдырылган фатирларда яшәсәк, бәлкем бу ярлану хатын да язмас идек. Тиздән район Советы сессиясе үткәрелергә тиеш, бәлкем анда безнең үтенечебезне дә игътибар үзәгенә алырлар.

П. ИСАЕВ,
II группа Бөек Ватан сугышы инвалиды һәм хезмәт ветераны.
К. БИЛДАНОВ,
хезмәт ветераны, пенсионер.
һ. б. барлыгы 190 имза.

ТАТУ ГАИЛӘДӘ

Районыбыз игенчеләре республикада беренчеләрдән булып изге бурычны— урып-җыюны төгәлләп чыктылар. Бу җиңүдә кырда көнне төнгә ялгап эшләүче комбайнчыларның, механизаторларның, шоферларның да, кырдан кайткан икмәкне эшкәртеп-урнаштырып торучы ындыр табагы хезмәтчәннәренең дә, уракта катнашкан техниканың төзеклеген тәэмин итүче ремонт службаларының да лаеклы өлеше бар.

Җиң сызганып дәртләнеп эшләгән кебек, гөрләтеп ял да итә беләләр авыл эшчәннәре. Күптән түгел уракны төгәлләү хөрмәтенә Единение поселогы янында урман аланында үткәрелгән уңыш бәйрәме шуны ачык күрсәтте.

Аңа барлык хуҗалыклардан җитәкчеләр, профсоюз комитеты рәисләре белән берлектә комбайнчылар, шоферлар, белгечләр һәм икмәк язмышын хәл итүгә үзеннән лаеклы өлеш керткән башка күп авыл эшчәннәре чакырылган иде.

Бәйрәмгә килүчеләрне аланның тирә-ягына урнашкан азык-төлек, өс һәм аяк киемнәре, көнкүреш кирәк-ярагларының заманасына күрә бай гына ассортиментын тәкъдим итүче сәүдә хезмәткәрләре ачык йөз белән каршы алдылар. Монда хуш исле кыздырмадан да авыз итәргә мөмкин иде.

Ә мәйдан түрендәге бәйрәмчә бизәлгән ясалма сәхнәдә халык зур сорау белән кулланa торган көнкүреш әйберләре, киемсалым, аяк киемнәре сату буенча аукцион оештырылды. Тегелгән һәм бәйләгән яңа фасонлы өс киемнәрен күрсәтү бигрәк тә яшьләрнең игътибарын җәлеп итте. Сәхнәдә аларның чыгышын район культура йорты үзешчән сәнгать осталары алыштырды.

Ә аланда бу вакытта теләгәннәр спорт төрләре буенча көч сынаштылар. Эштә сынатмаган ир-егетләр монда да үзләренең көч-гайрәтләрен күрсәттеләр.

Менә кунакларны бәйрәм табыны артына чакырдылар. Уракта катнашучы кыр батырларын һәм аларга ярдәмгә килгән Норлат предприятиеләре эшчеләрен бу зур җиңү белән халык депутатларының район Советы рәисе Х. Х. Морадыймов котлап чыгыш ясады. Аннан соң 1991 елгы урак йомгаклары буенча халык депутатлары район Советының агропромышленность комплексы, промышленность, төзелеш, транспорт, элемтә буенча даими комиссия рәисе Ә. В. Мөлеков доклад белән чыкты.

Соңыннан урак алдынгыларына бүләкләр тапшырылды.

Быелгы урак батыры булып «40 лет Победы» исемендәге колхоздан **Хәмит Кашапович Кыямов** танылды. Ул үзенең «ДОН-1500» комбайнында 11318 центнер ашлык суктырды. Ул Мактау грамотасы һәм төсле телевизор белән бүләкләнде. «ДОН-1500» комбайнында 10374 центнер ашлык суктырып икенче урында «Большевик» колхозыннан былтыргы урак батыры **Александр Егорович Донсков** аталды. Ул Мактау грамотасы һәм тегү машинасы белән бүләкләнде. Өченче урынга 10040 центнер ашлык суктырып «Восход» колхозыннан **Василий Дмитриевич Абрамов** чыкты. Аңа Мактау грамотасы һәм кер юу машинасы тапшырылды..

Ә «Нива» комбайнында суктыручылардан XXI партсъезд исемендәге колхоздан **Сәмигулла Шәрыпович Ситдыйков** (5622 центнер), «Алга»дан **Владимир Алексеевич Матвеев** (5521 центнер) һәм «Комбайн» колхозыннан **Әсхать Баһаветдинович Әхмәтов** (5450 центнер) алдынгылар дип табылды. Алар Мактау грамоталары, суыткыч, кер юу һәм тегү машиналары белән бүләкләнделәр.

«Комбайн» колхозыннан СК-5 комбайнында ЖВН-6 ургычы белән 900 гектар ашлык урдырып **Илгиз Борисович Шәйдуллин** беренче урынны яулады. Ул Мактау грамотасы һәм кер юу машинасы белән бүләкләнде.

Бәйрәмдә ашлыкны кырдан ындыр табакларына ташып торучы шоферларга да мактау сүзләре әйтелде һәм кыйммәтле бүләкләр тапшырылды. Биредә тагын күп уңыш алуга ирешкән колхозларның, бүлекчәләрнең, аерым бригадаларның исемнәре аталды, алар да бүләккә лаек булдылар.

Хезмәтенә карап һәркем хөрмәтен дә алды. Аларның һәрберсе турында безнең газетада тагын аерым сүз булачак әле. Ә бүген биредә бәйрәм, җыр, музыка, шатлыклы йөзләр...

Гомумән, бу яшел алан очрашу-күрешүләр, төрле хуҗалыктан килгән кыр эшчәннәренең аралашу урыны булды.



Бәйрәмнең күңелле, катнашучыларның күңеленә хуш килерлек итеп үтүендә аны оештыручыларның зур тырышлыгын да әйтми мөмкин түгел.

Кыскасы, күркәм, тату гаиләдәге кебек бергә эшләдек, бергә күңел ачтык.

Р. ШӘЙХУЛЛИНА.

Виктор Борисович Никитин 53 нче төзү-монтаж идарәсе башкарган һәр эшне башлаучы. Моны шулай диюнең сәбәбе аның экскаватор белән эшләвендә: теләсә нинди объект нигездән башлана ич. Никитин исә аны ышанычлы итү өчен йөкләтелгән вазифасын намус белән башкара. Инде дистә елга якын шушы хезмәтне үтәүче Борис Викторович—идарәдә ихтирамлы төзүчеләрнең берсе.

Рәсемдә: В. В. Никитин.

Базар мөнәсәбәтләренә күчкәндә

«КАЗАН» нәселле ат заводының даны киң таралган. Биредә йөк атлары, юртаклар үрчетелә. Сабантуйлар чорында ат заводының җилдән җитез чабышкылары ярышларда катнашмый һәм призлы урыннарны яуламый калмыйлар.

Биредә кымыз цехы да эшли. Базар мөнәсәбәтләренә күчкән чорда монысы өстәмә табыш өчен кирәк. Бу цехта елына 45 мең литр шифалы эчемлек ясала.

● Ничек яшисең, эшче?

Сыната торганнардан түгелләр

Адым саен тузан өермәсе күтәрелә. Әллә юри шаярта инде бу җил. Ул шулкадәр көчле исә ки, басудагы известь тузаны еракларга ук очып китә. Тракторчылар аптырадылар. Гадәттә мондый шартларда аны сибәргә дә рөхсәт итмиләр. Шулай да Нәзир белән Альбертның җитәкчене күрмичә эшне ташлап китәселәре килмәде. Аннан, җилнең дә туктавы бар. «Агропромхимия» берләшмәсендә Нәзир Кәримов үзе бишенче елын эшли. Норлат шәһәренә Аксубай районының Карасу авылыннан килеп урнашкан иде. Баштарак тимер юл депосында тепловоз машинисты ярдәмчесе булып эшләп карады. Ләкин андагы бу хезмәт күңеленә ятып бетмәде. Биредә аңар җиңелрәк, Нәзирләрнең эше шундый, алар колхоз һәм совхоз басуларына органик, минераль ашламалар, сусыз аммиак чыгаралар. **Кыскача итеп әйткәндә, югары сыйфатлы ашлык алу өчен җирне сыйлыйлар, киләсе ел уңышы турында алдан ук кайгыртучанлык чаралары күрәләр.**

Нәзиргә известьны төяп торучы К-700 тракторчысы Рамил Вәлиев икән. Аның да хезмәт стажы әлләни күп түгел әле: дүртенче елы гына...

«Агропромхимия» берләшмәсе коллективында яшьләрнең күп булуына бер караганда гаҗәпләнергә дә

кирәкми. Күп вакытларын юлда үткәрәләр, бу исә яшь кешеләр өчен кулайрак.

Ульянов исемендәге колхозның үзәк юлында фермадан кырга органик ашлама чыгаручы Исламгәрәй Сәидович Курамшин белән ничек килешмисең ди:

—Хәзер элекке еллар түгел инде, берләшмәдә җылы гаражлар барлыкка килде, рәхәтләнеп эшләргә була,—диде ул.

Чыннан да Исламгәрәй Сәидович кебек замана **балаларына барысын да үз башларыннан кичерергә туры килде. Колхоз, совхозларда куныл яткан чаклары аз булдымы?**

Хәзер исә, ничек җайлы. Юлда машинаның көпчәге тишелә икән, аңар алмашны куялар. Хуҗалыклардан кайта алмый торган очракларда да кайгыртып йөрмиләр, вахта машинасы килеп ала. Аннан тракторларда салкыннан куырылып утырмыйсың, кабина эчләре җылы һәм якты. Стартерга бассаң, тракторы кабына. Шнур белән тартып җәфаланасы юк. Уен уйнаган шикелле генә.

Исламгәрәй Сәидович баштагы чорда ДТ-75 тракторын йөрткән. Кизләү авылына (ул еллардагы «Сталинград» колхозына) Норлат шәһәреннән җом тащыган. Юлда нинди генә авырлыкларга юлыкса да, үзенең корыч айгырыннан аерылмаган. 1962 нче елга кадәр шулай эшли ул. 1963 нче елда Мәләкәс шәһәрендә берьеллык тракторчылар курсларын тәмамлый.

Оренбург өлкәсендә дә шул һөнәре буенча тырыш хезмәт куя.

Үзенең туган якларына кире әйләнеп кайткач янә басу-кырларга юл тота. Җәен комбайн штурвалы артына утырып игеннәрне урып-җыюда катнаша, кышын исә терлекләргә азык базыннан силос кертә. Тора-бара ул ремонт-техника предприятиесенә күчә. **Хезмәт хакы аз булса да, хезмәттәшләре кебек шуна риза булып яши һәм эшли.**

«Агропромхимия» берләшмәсе оешкач исә бирегә күчә. Мондагы коллективны үзара дус-тату яшиләр дип әйтергә тулы нигез бар. Өч төрле миллә халкы—русы, татары, чувашы бер-берсен хөрмәт итәләр һәм кимсетмиләр.

КамАЗ машинасының ягулык аппаратурасын көйләп торганда Әнәс Исмәгыйлевич Ибраһимов белән дә танышырга туры килде. Татарча нык акцент белән сөйләшсә дә, сүзгә кесәгә керми тагы:

—Мин гаепле түгел бит инде туган телне әйбәт белмәгәнгә,—ди көлеп. —Карелиядә туып-үстем. Шулай да татарча сөйләшүдән оялмыйм.

Әнәс Исмәгыйлевич эш шартларыннан зарланмады:

—Сауна, душыбыз, үз ашханәбез бар,—диде ул горурлык белән.—Эшче кеше өчен болары да җитә.

«Агропромхимия» берләшмәсендә эшләүчеләр өчен шатланырга кала. Агымдагы елда 8 айлык планнарны да коллектив уңышлы үтәгән. 867 мең сум урынына 1.193 мең сумлык эш башкарган, җиде айда 4.409 мең сум урынына 6.490 мең сумлык минераль ашламалар саткан. Мондый әйбәт күрсәткечләргә **алар Исламгәрәй Сәидович Курамшин, Нәбир Сабирҗанович Кәримов, Александр Петрович Убамзаров, Николай Михайлович Мөхәммәтҗанов, Юрий Владимирович Курочкин кебек** эшчеләрнең тырышлыклары аркасында ирешкәннәр. Болай эшләгәндә коллективның киләчәктә дә сынатмаячагына шик юк.

Г. РӘХИМОВА.

◆ *Футбол күзәтү*

Лаеклы җиңү

Иртән эшкә килгәч, шикәрчеләр поселогында яшәүче хезмәттәшем сорап куйды: «Кичә футбол матчы дулкынландыргыч булды, ахрысы, тамашачылар тавышы безгә кадәр ишетелде».

Әңгәмәдәшемнең фикере дөреслеккә туры килә иде. 28 августта шәһәр стадионында мөннәрчә футбол сөюче катнашында узган матч гаять киеренке, киеренке көрәш шартларында үтте. Андый вакытта, билгеле инде, тамашачылар хисләре тышка бәреп чыга.

Очрашуга килгән Зеленодольскиның «Авангард» командасы ТССР беренчелегенә ярышта бездән алдарак, өченче призлы урында тора иде. Үзләрендә үткән очрашуда «Факел»ны 2:0 белән отып җибәрүе дә көндәшләребезнең көчен исбатлый.

Әмма, ничек кенә булмасын, алдагы ике янәшә оттырыштан соң бигрәк тә, норлатлылар реванш алу теләге белән чыктылар кырга. Шуңа күрә беренче минутларда ук һөҗүмгә омтылдылар. Ләкин «Авангард», алда әйтелгәнчә, тешеп калганнардан түгел, безнекеләргә иркенләп уйнарга ирек куймады.

Беренче таймда якташларыбыз күп көч куйса да, шул сәбәпле кунакларның өстенлеге сизелә килде. Һәм 37 минутта кунаклар һөҗүмчесе Локман Баһаветдинов безнең капкага туп кертте.

Икенче таймның беренче минутларында да кунаклар активрак иде, исәпне арттырырга тырышып карадылар. Шундый кискен моментта тамашачыларның тоташ булышлыгын тоеп торган якташларыбыз психологик киртәне уза алдылар, кунакларга басым ясадылар. Каршы як капкасына шактый еш куркыныч яный башлады. Шундый бер очракта бәхәсле хәл дә килеп туды: туп капка линиясенә кереп өлгергән төсле тоелды. Судья, линиядәге арбитр белән киңәшеп, ул капкага кермәгән дигән нәтиҗәгә килде.

Бу норлатлыларга гайрәт өстәде. Шуннан соңгы вакытта алар басымны көчәйттеләр. Инициатива алар кулына күчте. Стадиондагы халык гөж килеп аларга куәт биреп торды.

72 минутта кунакларның берсе уен кагыйдәләрен бозган өчен штраф тибү билгеләнде. Капкадан 25 метрлар ераклыкта булуга карамастан аны Газинур Хәмидуллин төгәл башкарды: туп көндәшләрнең стенкасы өстеннән узып капкага килеп керде.

Якташларыбыз оттырудан котылу белән генә чикләнеп калмадылар, янә алга ташландылар. Кунаклар да җиңүнең кулдан ычкынуын теләми иде, шуңа күрә калган вакыт кызу темпта, ике яктан да һөҗүм шартларында барды. Ике капка янында да куркыныч моментлар туа торды. 88 минутта безнең капкага штраф тибү билгеләнде. Хәтәр килгән тупны капкачы Владимир Зайцев тотты, тамашачыларның көчле алкышлавына лаек булды.

Шуннан соңгы ике минутта очрашуның язмышы хәл ителде. Башлап «Авангард» капкасына таба почмактан тибү билгеләнде. Кунаклар аны кәчкә кире кактылар. Ул да түгел, безнең футболчылар янә туп белән штраф мәйданчыгына үтеп керделәр. Кунаклар аларның берсен этеп екты. 11 метрдан штраф тибү билгеләнде. Аны беренче гол иясе Газинур Хәмидуллин типте, командага җиңү китерде. Максатчан, күмәк тырышлык, осталык һәм күп көч куеп яуланды ул, лаеклы җиңү булды.

Р. АЙЗАТУЛЛИН.

Киекле авылында яшәүче әниебез Сәкибә Шәйдулла кызы Садыйкованы 50 яше тулуы белән котлыйбыз. Кадерле әниебезгә нык сәламәтлек, бәхет, тыныч тормыш телибез.

ТОРМЫШ ИПТӘШЕ, УЛЛАРЫ, КИЛЕННӘРЕ, ОНЫКЛАРЫ.

x x x

Түбән Норлат авылында яшәүче кадерле әниебез Сәвия Моктәсиб кызы Әхмәдиевага август ахырында 55 яшь тулды. Аны туган көне белән ихлас күңелдән тәбрикләп, саулык-сәламәтлек, бәхет, шатлыклар, кайгы-хәсрәтсез көннәр, әтиебез белән бергә тату, озын гомер кичерүләрен телибез.

Өч бала тәрбияләп үстергән, кечкенәдән үк тормышның ачысын-төчесен татып та, барыбер һәрвакыт киң күңелле, сабыр һәм кайгыртучан булган әниебезгә чын йөрәктән рәхмәтебезне белдерәбез.

ИҢ ИЗГЕ ТЕЛӘКЛӘР БЕЛӘН БИ АНАСЫ, ТОРМЫШ ИПТӘШЕ, УЛЛАРЫ ФИРДӘВЕС, ФИРДҮС, КИЛЕННӘРЕ ДИНИЯ, РАЗИЯ, КЫЗЫ ЛӘЙСӘН, КИЯВЕ ВӘЛИЯР, ОНЫКЛАРЫ РӘЗИНӘ, РАЗИЛ, РӘЗИЛӘ, ГӨЛҮС, НАИЛ.

ТЕЛЕВИДЕНИЕ

СИШӘМБЕ
3 СЕНТЯБРЬ
КАЗАН КҮРСӘТӘ

18.05 Чаллыдагы «Энергетик» мәдәният сараеның «Айгөл» балалар ансамбле чыгышы.
18.35 Редакциягә хат килде...
19.00 Татарстан.
19.30 Әлли-бәлли-бәү.
19.40 «Кешеләр һәм эшләр». Түбән Кама районының «Красный Ключ» кошчылык фабрикасы.

I ПРОГРАММА

6.30 Иртә.
9.00 Балалар сәгате.
10.00 «Гардемариннар, алга». 1 серия.
11.20 Хоккей. Канада кубогы. СССР—Швеция жыелма командалары. 1 период.
12.00 «ТЯХ».
12.10 Хоккей. Канада кубогы. СССР—Швеция жыелма командалары. 2 һәм 3 периодлар.
13.45 Мультфильм.
15.00 «ТЯХ».
15.10 Нәфис телефильм: «Командировка». 1 серия. «Наталья».
16.15 Концерт.
16.40 Документаль телефильм: «Дөнья—тантана».
17.05 Балаларның музыка клубы.
17.30 Чемпионнар белән бергә.
18.05 «Иске танышларның гаилә хроникасы» циклын тәкъдим итү.
18.25 Блокнот.
18.30 «ТЯХ».
18.45 Караш.
19.30 Һәвәсләр дөньясы.
19.45 «Гардемариннар, алга». 2 серия.
21.00 Вакыт.
21.40 Останкино концерт студиясендә язучы Т. Зөлкәрнәев белән очрашу.
23.05 «ТЯХ».
23.20 Хоккей. Канада кубогы. Канада—АКШ җыелма командалары.
01.35 «Гардемариннар, алга». 2 серия.
02.45 Фильм-балет. «Мизгелләр».

II ПРОГРАММА

8.00 Иртәнге гимнастика.
8.20 Мультфильмнар.
8.50 Документаль телефильм: «Флейта».
9.20 Адам Смит акчалары дөньясы.
10.00 Француз теле. Беренче уку елы.
10.30 Ритмлы гимнастика.
11.30 Француз теле. Икенче уку елы. Россия телевидениесе программасы.
11.30 Россиянең документаль экраны. «Княгиня Наталья Петровна».
12.30 Музыкаль программа.
13.30 Нәфис телефильм: «Офык артына баручылар». 1 серия.
14.35 Коми АССРның «Асья Кыа» Дәүләт җыр һәм бию ансамбле концерты.
17.00 «Татулашу атнасы». СССР һәм Германиянең икенче Бөтендөнья сугышында катнашучы ветераннар очрашуы.
17.30 Дөнья базарына ачкыч. Россия телевидениесе программасы.

ЧӘРШӘМБЕ
4 СЕНТЯБРЬ
КАЗАН КҮРСӘТӘ

18.05 «Малахит тартма». Телефильм-концерт.
18.35 Реклама.
18.40 Лидия Әхмәтова җырлый.
19.00 Татарстан.
19.30 Юл хәвефсезлеге өчен.
19.50 Әлли-бәлли-бәү.
20.00 Телесеанс. Яшьләр программасы.

I ПРОГРАММА

6.30 Иртә.
9.00 Балаларның музыка клубы.
9.45 Чемпионнар белән бергә.
10.00 «Гардемариннар, алга». 2 серия.
11.10 Мультфильм.
11.20 Канада кубогы. Канада—АКШ җыелма командалары. 1 период.
12.00 «ТЯХ».
12.10 Хоккей. Канада кубогы. Канада—АКШ җыелма командалары. Тәнәфестә (12.50)—Менеджерлар мәктәбе.
15.00 «ТЯХ».
15.15 «Командировка». 2 серия.—«Шурочка, Петя Шутов һәм башкалар».
16.00 Документаль телефильм: «Онытылган кораблар язмышы».
16.50 Балалар сәгате.
17.50 Биржа очучысы.
18.00 Мультфильмнар.
18.25 Блокнот.
18.30 «ТЯХ».
18.45 Планета.
19.30 Һәвәсләр дөньясы.
19.45 Мультфильм.
19.55 «Гардемариннар, алга». 3 серия.
21.00 Вакыт.
21.40 Документаль телефильм премьерасы: «Иске танышларның гаилә хроникасы». «Света». 1 һәм 2 фильмнар. Тәнәфестә (22.25)—Актуаль репортаж.
23.30 Телевизион яңалыклар хезмәте.
23.50 Н. Гнатюк җырлый.
00.30 «Парадиз-коктейль». 2 нче чыгарылыш.
01.30 «Гардемариннар, алга». 3 серия.
02.35 Документаль телефильм: «Варлам Шаламов. Минем берничә тормышым».

II ПРОГРАММА

8.00 Иртәнге гимнастика.
8.20 Мультфильмнар.
8.50 «Шагыйрь йорты». М. Волошин.
9.45 Немец теле. Беренче уку елы.
10.15 Күп белүчеләр өчен күнегү.
11.00 Немец теле. Икенче уку елы. Россия телевидениесе программасы.
11.30 Документаль фильм.
12.20 «Нәрсә күрсәм—шуның хакында җырлыйм». Концерт.
13.10 Телевизион фильм.
13.30 Нәфис телефильм: «Офык артына баручылар». 2 серия.
14.40 Делегатскаядагы музей. «Рус кием-салымы».
17.00 Мәскәүнең зур бүләге. Супермотокросс буенча халыкара ярышлар.
17.45 Мультфильм. Россия телевидениесе программасы.
18.00 Кырлар.
19.00 Визит карточкасы.
20.00 Хәбәрләр.

Җир участогы кирәксә

Норлат-Октябрь ит комбинаты 27 гектарда җир участогы бүлә. Бу җирләр Норлат шәһәре эшчеләре һәм хезмәткәрләренә коллектив бакчачылык өчен исәпләнгән. Участок «Большевик» колхозы җирендә Осиновка торак пункты янында урнашкан.

Коллектив бакчачылык участоклары кирәксенгән оешмалар һәм учреждениеләр язма рәвештә заявка бирә алалар. Заявкада участокка ихтыяҗы булган кешенең исеме, фамилиясе язылырга тиеш. Алар Октябрь районының җир реформасы һәм җир ресурслары буенча комитетына тапшырыла. Ә комитет район Советы халык депутатлары башкарма комитетының икенче катында урнашкан.

Р. ХӘСӘНОВ.

? СОРАГЫЗ — җавап бирәбез

Норлат шәһәрендә яшәүче Н. Фәттахова редакциягә сорау белән мөрәҗәгать итте.

«Мин июль—август айлары өчен талонга шикәр комы ала алмыйча калдым. Сентябрь аенда бу талоннарга продукция бирелерме икән?»—диде ул. Без бу сорауны район потребительләр җәмгыяте рәисе Һ. Х. САДЫЙКОВка юлладык.

Ул болай дип җавап бирде: «Җәйге ай талоннарына шикәр комы 1 октябрьгә кадәр биреләчәк».

«Яшь көч» колхозы идарәсе һәм профсоюз оешмасы әнисе
ШӘМҖИЯН МИНЗАҺИТ кызының
вафат булуы сәбәпле колхоз рәисе Х. М. Абделганиевның кайгысын уртаклашалар.

«Яшь көч» колхозы бухгалтериясе хезмәткәрләре әнисе
ШӘМҖИЯН МИНЗАҺИТ кызының
вафат булуы сәбәпле Хәсән Минвәли улы Абдулганиевның, мәрхүмәнең башка якыннарының һәм туганнарының кайгысын уртаклашалар.

МӨХӘРРИР Ә. У. АВДУЛЛИН.

Учредитель: халык депутатларының Октябрь район Советы.
Газетада язмалары басылган авторларның фикерләре бу әле редакция фикере дигән сүз түгел.

РЕДАКЦИЯНЕҢ АДРЕСЫ: 423000, Норлат шәһәре, К. Маркс урамы, 19.
ТЕЛЕФОННАР: мөхәррир—2—12—14, 2—22—81, мөхәррир урынбасары—2—10—44, рус теленә һәм чуваш теленә тәрҗемә буенча мөхәррир урынбасарлары—2—15—63, социаль-экономика бүлеге— 2—22—51, җаваплы секретарь—2—14—16, хатлар бүлеге һәм бухгалтерия—2—18—67.

Газетаны Фидания ХӘЙРЕТДИНОВА җыйды. Римма ГАНИЕВА верстка ясады. Клара БОБКОВА басты. Корректор Зөлфия ВӘЛИЕВА.

«Дуслык» газетасы атнаның сишәмбе, пәнҗешәмбе, шимбә көннәрендә чыга һәм рус, чуваш телләренә тәрҗемә ителә.
Нәшрият, полиграфия һәм китап сәүдәсе буенча ТССР Дәүләт комитетының Октябрьның 50 еллыгы исемендәге Норлат-Октябрь типографиясе.
Күләме—1 басма табак. Заказ 105. Тираж 3415.